География фәненнән
шәһәр күләмендә үткәрелә торган олимпиада сораулары

9 нчы сыйныф

Эш вакыты – 180 минут
Гомуми балл – 80

1.Түбәндә бирелгән регионнарның кайсысы Урал федераль округына керми?

а) Курган өлкәсе
б) Төмән өлкәсе
в) Чиләбе өлкәсе
г) Оренбург өлкәсе

2.Хакасларның кайсы тел семьялыгына керүен ачыклагыз

а) Индоевропа
б) Урал-юкагир
в) Алтай
г) Тунгус-маньчжур

3.Россиядә кеше саны буенча уртача саналган шәһәрләрдә кеше саны:

а) 20 меңгә кадәр
б) 50 меңгә кадәр
в)100 меңгә кадәр
г)500 меңгә кадәр

4.Түбән Новгород шәһәренә кайсы елны нигез салганнар?

а) 1221
б) 1273
в) 1314
г) 1356

5.Ириклинск электр станциясе кайсы тип станцияләр рәтенә керә?

а) АЭС
б) ГЭС
в) ТЭС
г) геотермаль

6.Бирелгән чыганакларның кайсыларында нефть табыла?

а) Интинское
б) Назаровское
в) Фролово
г) Самотлор

7.Бирелгән чыганакларның кайсыларында алюминий рудасы табыла?

а) Коршуновское
б) Сулея
в) Садон
г) Хибинское

8.Гидролизлы (гидролизное) җитештерү вакытында нәрсә табыла?

а) сода
б) су
в) спирт
г) целюлоза

9.Азотлы ашламалар авыл хуҗалыгында нинди төп роль уйныйлар?

а) җирнең уңдырышлылыгын арттыралар
б) культуралы үсемлекләрнең үсү тизлеген арттыралар
в) бөртекле культураларда калий күләмен арттыралар
г) бөртекле культураларда аксым күләмен арттыралар

10. 2000 еллап элек Везувий вулканы активлашу аркасында нинди шәһәрләр юкка чыккан? (дөрес җавапларны сайлап алырга)

а) Геркуланум
б) Стабия
в) Библ
г) Тир

11. Халыкара географик союз кайсы елда оештырылган?

а) 1908
б) 1922
в) 1928
г) 1937

12.Бу приборда, җилнең тизлеге, аның хәрәкәтләнүче өлешенә (вертушкага) басым ясау нәтиҗәсендә билгеләнә. Приборның исемен бирелгән вариантлар арасыннан табарга.

а) гигрометр
б) флюгер
в) анемометр
г) психрометр

13.Валдай калкулыгыннан башланучы елгалар арасында кайсысы артык?

а) Волга
б) Төньяк Двина
в) Көнбатыш Двина
г) Днепр

14.Безнең илне юучы диңгезләрнең саны ничә?
а) 9
б) 11
в) 13
г) 15

15.Россиянең кайсы шәһәрләре фәнни-җитештерү үзәкләр булып санала?

а) Ставрополь
б) Дубна
в) Обнинск
г) Ногинск

16.Бирелгән картада кайсы өлкә күрсәтелгән? Бу өлкә кайсы икътисади район һәм кайсы федераль округ составында? Хужалыгында нинди промышленность тармаклары зур үсеш алган?

17.Иҗтимагый географиядә _____ районнарга бүлү (районирование) белән беррәттән _____ районнарга бүлүне (районирование) кулланалар.

18.Россиядә сарыкчылыкның төп тармагы _____. Бу тармак аеруча илнең _____ һәм _____ өлешләрендә киң таралган.

19. Үзенчәлекле икътисадый зоналарның (особые экономические зоны (ОЭЗ)) специальләшү тармакларын ачыклап таблицаны тутырыгыз

Үзенчәлекле икътисадый зоналар (Особые экономические зоны(ОЭЗ))	**Специальләшү тармаклары**
Санкт-Петербург шәһәре	
Дубна шәһәре, Мәскәү өлкәсе	
Томск шәһәре	
Липецк шәһәре	
Алабуга шәһәре	

20. Түбәндә, Россиянең бер регионының флагы һәм гербы күрсәтелгән ? Бу кайсы субъект? Регионда гы төп промышленность тармакларын һәм үзәкләрен атагыз.